**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасындагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 24 гыйнварындагы ПУ-44 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-754 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы һәм 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы һәм 2014 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2014 елның 22 июлендәге ПУ-708 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы һәм 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 2 кисәгенең 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) « Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Аппараты Матбугат үзәге җитәкчесе 02-1-1-05 »

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

« Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат үзәге җитәкчесе 02-1-1-05 »;

б) « Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты бүлек мөдире урынбасары 02-1-2-08 »

позициясеннән соң түбәндәге позицияне өстәргә:

« Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат үзәге җитәкчесе урынбасары 02-1-2-08[1] ».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-234 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2013 елның 5 августындагы ПУ-715 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы, 2014 елның 17 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы һәм 2014 елның 7 августындагы ПУ-761 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 кушымтага, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-646 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-941 номерлы указлары нигезләмәләрен исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Матбугат үзәге җитәкчесе | 02-1-1-05 | 6100 |

»

позициясен

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат үзәге җитәкчесе | 02-1-1-05 | 7957 |

»

позициясенә алмаштырырга;

б) «

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты бүлек мөдире урынбасары | 02-1-2-08 | 5490 |

»

позициясеннән соң түбәндәге позицияне өстәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат үзәге җитәкчесе урынбасары | 02-1-2-08[1] | 7163 |

».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 25 март
№ ПУ-285